**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 март № 191

г. Казань

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркын төзү турында

Татарстан Республикасының сәнәгать инфраструктурасы объектларын үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең (алга таба – «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционерлык җәмгыяте) «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы территориясендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркын (алга таба – «Алабуга-2» индустриаль паркы) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционерлык җәмгыятен «Алабуга-2» индустриаль паркы белән идарә итүче компания итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, «Алабуга-2» индустриаль паркының инфраструктура объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) төзекләндерү максатларында, «Алабуга» СҖТ МИЗ» акционерлык җәмгыяте идарә итүче компаниясенең 2017 елда субсидия бирү күләмнәре һәм чыганаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\191.docx